**ИСПОЛНИТЕЛЬНЫЙ КОМИТЕТ КАМСКО-УСТЬИНСКОГО МУНИЦИПАЛЬНОГО РАЙОНА РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН**

**ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ КАМА ТАМАГЫ МУНИЦИПАЛЬ РАЙОНЫ БАШКАРМА КОМИТЕТЫ**

ул. Калинина, д.31,
пгт. Камское Устье, 422820

Калинин урамы, 31 йорт,
штп. Кама Тамагы, 422820

тел.: (884377) 2-18-85, факс: 2-20-70, e-mail: Kamuste.Ispolkom@tatar.ru, http://kamskoye-ustye.tatarstan.ru.

---

**ПОСТАНОВЛЕНИЕ** **КАРАР**

23.11.2020 № 1138

Татарстан Республикасы Кама Тамагы муниципаль районы Башкарма комитетының «Авыл җирендә, эшчеләр поселокларында (шәһәр тибындагы поселокларда) эшләүче һәм яшәүче аерым категориядәге гражданнарга торак һәм коммуналь хезмәтләр өчен түләү буенча социаль ярдәм чаралары турында» 2006 елның 22 декабрендәге 172 номерлы карарына үзгәрешләр кертү хакында

«Мәгариф турында» Татарстан Республикасы Законының 14 һәм 25 статьяларына үзгәрешләр кертү хакында» 2020 елның 18 июлендәге 38-ТРЗ номерлы Татарстан Республикасы Законы нигезендә Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының «Авыл җирендә, эшчеләр поселокларында (шәһәр тибындагы поселокларда) эшләүче һәм яшәүче аерым категориядәге гражданнарга торак һәм коммуналь хезмәтләр өчен түләү чаралары турында» 2005 елның 20 апрелендәге 192 номерлы карары нигезендә мәгариф оешмалары хезмәткәрләренә социаль ярдәм чаралары күрсәтү максатларында, Кама Тамагы муниципаль районы Башкарма комитеты КАРАР БИРӘ :

1. Татарстан Республикасы Кама Тамагы муниципаль районы Башкарма комитетының «Авыл җирендә, эшчеләр поселокларында (шәһәр тибындагы поселокларда) эшләүче һәм яшәүче аерым категориядәге гражданнарга торак һәм коммуналь хезмәтләр өчен түләү буенча социаль ярдәм чаралары турында» 2006 елның 22 декабрендәге 172 номерлы карарының 1 пунктына түбәндәге үзгәрешне кертергә:

1.1. 1 пунктның дүртенче абзацын «педагогик хезмәткәрләргә» сүзләреннән соң «авыл торак пунктларында яшәүче һәм эшләүче мәгариф оешмалары җитәкчеләренә һәм аларның урынбасарларына, мәгариф оешмаларының структур бүлекчәләре җитәкчеләренә һәм аларның урынбасарларына» сүзләрен өстәргә.

2. Әлеге карарның үтәлешен тикшереп торуны Кама Тамагы муниципаль районы Башкарма комитеты җитәкчесенең социаль мәсьәләләр буенча урынбасары Е.В. Сороковнинага йөкләргә .

Җитәкче Р.М. Заһидуллин